**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Кукеевского**
**сельского поселения**
**Рыбно Слободского**
**муниципального района**

**Новая ул., дом 5,**
**с.Кукеево, 422669**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Куки**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

**Яна урамы, 5 нче йорт,**
**Куки авылы , 422669**

**Тел.: (84361) 30581 факс: (84361)30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**апреля 2023 года** **Күки авылы** **№ 3**

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмөшле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында»

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, “Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 11 ноябрендәгы 261-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Яктырту җайланмалары, электр лампаларын җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китемәслек итеп тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турынд» 2314 номерлы карарына нигезләнеп КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмөшле лампалар туплану урынын түбәндәгн адреска билгеләргә: Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт

2. Терекөмөшле лампалар кулланучы күпфатирлы йортлар милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары өчен эшкәртелгән терекөмөшле лампалар туплану урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган "Яктырту җайланмалары, электр лампаларын җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китемәслек итеп тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләре"нең 4 пункты нигезендә билгеләнелә.

3. Күпфатирлы йортларда терегөмөшле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмөшле лампаларның туплану урыннарын терекөмөшле лампаларны кулланучы күпфатирлы йорт милекчеләре, яллаучылры, биналардан файдаланучылары өчен дип тә билгеләргә.

4. Кулланылган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы Яңа урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан стендта куярга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6 Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы

А.М.Бәдретдинов